# Бикмөхәмәтов Сәетҗан Фәтхетдин улы

Бикмөхәмәтов Сәетҗан Фәтхетдин улы 1937 елның 5 январенда Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.

1944 елда Бәзәкә мәктәбенә укырга керә. 7 классны тәмамлагач колхозга эшкә керә. Анда комбайнер ярдәмчесе булып эшли, соңыннан күпмедер вакыт тракторда җир сөрә.

1956 елның 9 сентябрендә Совет армиясе сафларына хәрби хезмәткә алына. 1956-57 елларда Анапа шәһәрендә "Рулевой на кораблях противолодочной обороны" специальностенә әзерлек үтә. Аннан соң Хабаровск шәһәрендә противолодочный корабльдә рулевой-сигнальщик булып хезмәт итә (Амур елгасында, Кытай чигендә). 1959 елда демобилизацияләнеп авылга кайта.

1960 елда НГДУ "Прикамнефть"кә оператор булып эшкә керә. 1962 елда Мингазетдинова Минерәүфә Мөхәмәтдин кызына никахлаша. Бу никахта аларның 3 кызлары Ильсияр, Зөлфия һәм Инзилә туа. Аларның өчесен дә укытып олы тормыш юлына бастыралар.

1992 елга кадәр НГДУ "Прикамнефть"тә эшләп лаеклы ялга чыга. Хезмәтләре өчен Сәетҗан Фәтхетдин улы түбәндәге бүләкләргә лаек була:

1974 ел- "Победитель социалистического соревнования";

1989 ел- "Ветеран труда" медале;

1990 ел- "Ударник 12-й пятилетки"знагы;

1985, 1986, 1987 елларда НГДУ "Прикамнефть" нең почет грамоталары белән бүләкләнә.

Хәзерге вакытта тормыш иптәше Минерәүфә Мөхәмәтдин кызы белән Бәзәкә авылында яшиләр. 8 оыклары, 5 оныкчыклары бар.

Сәетҗан Фәтхетдин улы- Бәзәкә авылы мәчете шурасы вәкиле. 2021 елның 12 июнендә Бәзәкә авылы сабантуенда авыл халкына озак еллар дәвамында күрсәткән хезмәтләре өчен "Бәзәкә авылы каршындагы хезмәтләре өчен" почетлы знагы белән бүләкләнде.





*Бикмухаметов Саетзян*



*Хәрби хезмәттә, 1956-59 еллар. Хабаровск.*



*Гаилә мәҗлесе, 70 яшь, 2007 ел*



*Оныкчыгы Адель белән, 2017 ел*


Бәйрәм белән!





